КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 гыйнвар г.Казань № 37

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турында» 2016 ел, 17 август, 569 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турында» 2016 ел, 17 август, 569 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктта «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2021» саннарына алыштырырга;

4 нче пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турындагы нигезләмәдә:

8 нче пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Казан шәһәре, Петербург ур., 12 йорт» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Казан шәһәре, Сафьян ур., 5 йорт» сүзләренә алыштырырга;

13 нче пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия бирү комиссиясе составын бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 17 август, 569 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 25 гыйнвар, 37 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары
һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен
С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия бирү комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, комиссия рәистәше |
| Хохорин Артём Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры, комиссия рәистәше (килешү буенча) |
| Захматова Анна Андреевна | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Пивоварова Наталья Дмитриевна | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының территорияләр белән эшләү һәм төбәкара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы, комиссиянең җаваплы секретары |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әсәдуллина Алсу Мөниб кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Гарифуллина Илсөяр Хәләлетдин кызы | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретары |
| Җәләлева Анфиса Григорьевна | «Татарстан Республикасы урта һөнәри белемнең мәгариф учреждениеләре директорлары советы» коммерцияле булмаган партнерлыгы рәисе, «Казан педагогика көллияте» урта һөнәри белемнең дәүләт автоном мәгариф учреждениесе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Кыямов Руфат Рифгать улы | «Татарстан Республикасы студентлары лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президенты (килешү буенча) |
| Осипова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция участок вәкилләре һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләр эшчәнлеген оештыру бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Рыков Андрей Львович | «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Шакирова Гузәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы. |